МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.10.2025 Казан ш. № 209-ОД

Татарстан Республикасы территориясендә гомуми туклану хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырыла торган, килүчеләргә хезмәт күрсәтелүче сезонлы залларны (зоналарны) урнаштыру һәм төзекләндерүгә карата таләпләр турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» федераль законга һәм «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 29 маендагы 102-ФЗ номерлы федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аның әйләнеше һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 елның 5 августындагы 391 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аның әйләнеше һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 25 августындагы 632 номерлы карары нигезендә

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә гомуми туклану хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырыла торган, килүчеләргә хезмәт күрсәтелүче сезонлы залларны (зоналарны) урнаштыру һәм төзекләндерүгә карата әлеге боерык Кушымтасы нигезендә таләпләр расларга.

2. Әлеге боерык 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Н.Д.Закировка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының 2025 елның
_______________ _____
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы территориясендә гомуми туклану хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырыла торган, килүчеләргә хезмәт күрсәтелүче сезонлы залларны (зоналарны) урнаштыру һәм төзекләндерүгә карата таләпләр

1. Гомуми туклану хезмәтләрен күрсәткәндә гомуми туклану объектлары янында яисә гомуми туклану хезмәтләре күрсәтелгәндә алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырыла торган гомуми туклану объектларына янәшә урнашкан территориядә килүчеләргә хезмәт күрсәтелүче сезонлы залларда (зоналарда) (алга таба – сезонлы зал (зона)) алкоголь продукциясен ваклап сату гомуми туклану хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуга карата «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясында һәм күрсәтелгән федераль закон нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлгән очракта, шулай ук Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аның әйләнеше һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе яисә аның территориаль органнары тарафыннан гомуми туклану хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы юридик зат төземичә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр дип танылa торган шәхси эшкуарларга, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шулай ук гомуми туклану хезмәтләрен күрсәткәндә сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре һәм әчетелгән балны ваклап сату эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга һәм шәхси эшкуарларга бирелгән сезонлы залның (зонаның) әлеге таләпләргә туры килүе турында бәяләмә булганда гамәлгә ашырыла.

2. Сезонлы зал (зона) гомуми туклану объектына (алга таба – объект) якын территориядә, объектка килүчеләр өчен керү урыныннан сезонлы залга (зонага) керүгә кадәр ясалма һәм табигый киртәләрне исәпкә алмыйча, туры сызык буенча биш метрдан да артмый торган ераклыкта урнаштырыла яисә шундый объект урнашкан объектка яисә бинага (бүлмәгә) тоташа (шул исәптән объектның аерылгысыз өлеше).

3. Сезонлы залны (зонаны) календарь елның 15 апреленнән 15 октябренә кадәр урнаштыру рөхсәт ителә.

4. Сезонлы залны (зонаны) урнаштыру шәһәр төзелеше, архитектура, янгын

сүндерү, санитария нормалары, кагыйдәләр һәм нормативлар, ул урнашкан территориядә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәгән килеш, шулай ук шулай ук сезонлы зал (зона) урнашкан җир кишәрлегеннән файдалануга милек хокукы яисә башка законлы хокук булганда гамәлгә ашырылырга тиеш.

5. Сезонлы залны (зонаны) төзекләндерү халыкның хәрәкәте чикле төркемнәре өчен аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып башкарыла (пандуслар, тоткалар, персоналны чакыру төймәсен куллану юлы белән).

6. Сезонлы залны (зонаны) җиһазлау түбәндәгеләр белән тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып башкарыла:

а) сезонлы залның (зонаның) керү юлын һәм чикләрен билгеләргә мөмкинлек бирә торган декоратив киртәләр белән;

б) сезонлы залны (зонаны) дымлы җыештырырга мөмкинлек бирә торган каты өслек белән;

в) килүчеләр өчен өстәлләр һәм җиһазлар белән.

7. Сезонлы залны (зонаны) урнаштыру күрше җир кишәрлекләренең, шулай ук биналарның, бүлмәләрнең, төзелмәләрнең, корылмаларның милекчеләренең һәм алардан файдаланучыларның хокукларын бозмаска һәм җәяүлеләр һәм автотранспорт хәрәкәте өчен киртәләр тудырмаска тиеш.